**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

**КАРАР**

07 02 2025 ел № 181

«2025-2027 елларга Тукай муниципаль районының авыл яшьләре» район программасын раслау турында

Тукай муниципаль районы авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру максатында, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2019 елның 5 мартындагы 158 номерлы карары нигезендә

**КАРАР БИРӘ:**

1. «2025-2027 елларга Тукай муниципаль районының авыл яшьләре» район программасын кушымта нигезендә расларга.
2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.
3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Ю.П. Васильевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе К.Р. Нәҗмиев

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2025 елның 07 02 181 номерлы карарына кушымта

# «2025-2027 елларга Тукай муниципаль районының авыл яшьләре» район программасы

**Яр Чаллы шәһәре**
**2025 ел**

# ПРОГРАММА ПАСПОРТЫ

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2025-2027 елларга Тукай муниципаль районының авыл яшьләре» район программасы (алга таба - Программа) |
| Программаны эшләү өчен нигез | - «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон;<br>- «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы законы (2021 елның 5 маендагы 35-ТРЗ номерлы редакциядә);<br>- «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы карары;<br>- «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы карары белән расланган (2022 елның 5 ноябрендәге үзгәрешләр белән) «2019-2025 елларга Татарстан Республикасы авыл яшьләре» ярдәмче программасы |
| Программаны төп эшләүче | Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| Программаның максаты: | Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру |
| Программаның бурычлары | - Яшьләрнең социаль үсеше белән идарә итү, республиканың конкурентлык сәләтен ныгытуда аның иҗади потенциалыннан файдалану, яшь буынның тормыш сыйфатын яхшырту өчен оптималь шартлар тәэмин итү;<br>- авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру;<br>патриотик тәрбия системасын үстерү һәм модернизацияләү;<br>- иреклеле ярдәмчелекккә (волонтерлыкка) ярдәм итү һәм аны үстерү |
| Программаны төп башкаручылар | - Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге;<br>- «Тукай муниципаль районы мәгариф идарәсе» МКУ;<br>- Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге |
| Программаны тормышка ашыру вакыты һәм этаплары | Программаны тормышка ашыру 2025-2027 елларга исәпләнгән |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Районның җирле бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 17 612 700 сум тәшкил итә.<br>шул исәптән, еллар буенча:<br>2025 ел – 5 870 900 сум, шул исәптән Тукай муниципаль районының «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ агымдагы тотуга 4 773 900 сум;<br>2026 ел – 5 870 900 сум, шул исәптән Тукай муниципаль районының «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ агымдагы тотуга 4 773 900 сум;<br>2027 ел – 5 870 900 сум, шул исәптән Тукай муниципаль районының «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» МБУ агымдагы тотуга 4 773 900 сум.<br>Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм |

| | |
|---|---|
| | тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.<br>Республика, федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклардан средстволар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк |
| Муниципаль программаның максатларын һәм бурычларын гамәлгә ашыруның көтелә торган ахыргы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәсендә 2027 елга арттыру күздә тотыла:<br>- мәдәни-ял итү чараларында катнашучы яшьләр санын;<br>- ирекле ярдәмчелек эшчәнлегендә катнашучы яшьләр санын;<br>- яшьләрне гражданлык һәм патриотик тәрбияләүгә юнәлтелгән чараларда катнашучы яшьләр санын;<br>- сәламәт яшәү рәвешенә юнәлтелгән чараларда катнашучы яшьләр санын;<br>- яшьләрнең иҗтимагый-сәяси активлыгын арттыруга юнәлтелгән чараларда катнашучы яшьләр санын;<br>- балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегендә катнашучы яшьләр санын |

## 1. Программа хәл итүгә юнәлтелгән проблеманың характеристикасы

Әлеге муниципаль программа «Россия Федерациясендә яшьләр сәясәте турында» 2020 елның 30 декабрендәге 489-ФЗ номерлы Федераль закон, «Яшьләр һәм Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәте турында» 1993 елның 19 октябрендәге 1983-XII номерлы Татарстан Республикасы законы (2021 елның 5 маендагы 35-ТРЗ номерлы редакциядә) нигезендә «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү дәүләт программасын раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 елның 05 мартындагы 158 номерлы карары (2022 елның 5 ноябрендәге үзгәрешләр белән) белән расланган «2019-2025 елларга Татарстан Республикасы авыл яшьләре» ярдәмче программасын гамәлгә ашыру максатында эшләнде.

Программа чараларын гамәлгә ашыру «Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары (дәүләт хакимиятенең югары башкарма органнары җитәкчеләре) эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген бәяләү турында» РФ Президентының 2021 елның 4 февралендәге 68 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе субъектларының югары вазыйфаи затлары эшчәнлегенең һәм Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимият органнары эшчәнлегенең нәтиҗәлелегенә ирешүгә юнәлтелгән.

Муниципаль программа чаралары Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 4 февралендәге 63 номерлы карары белән расланган «2030 елга кадәр Татарстан Республикасы дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясе», «Россия Федерациясе Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2018 елның 31 октябрендәге 1288 номерлы карары, аерым алганда, «Социаль активлык» федераль проекты, «Мәгариф» илкүләм проектының «Патриотик тәрбия» проекты, «Татарстан Республикасы Хөкүмәтендә проект эшчәнлеген оештыру турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 20 июнендәге 504 номерлы карарлары бурычларына Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләре комплексында ирешүгә юнәлтелгән.

«2023-2025 елларга Тукай муниципаль районы авыл яшьләре» чараларын гамәлгә ашыру Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 21 октябрендәге 35/1 номерлы карары белән расланган 2016-2021 елларга һәм 2030 елга кадәрге план чорына Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының социаль-икътисадый үсеш стратегиясе бурычларына ирешүгә юнәлтелгән.

Яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлеше – яшьләрнең социаль, иҗади һәм һөнәри мөмкинлекләрен тормышка ашыру өчен мөмкинлекләр мохитен булдыру. Миссияне гамәлгә ашыру эшенең төп принцибы – яшьләр өчен бар нәрсә дә яшьләр белән генә. Төп бурычлардан

чыгып, Татарстан Республикасында дәүләт яшьләр сәясәтенең өстенлекле юнәлешләрен гамәлгә ашыруда төп максатчан юнәлешләр билгеләнде:

- нәтиҗәлелек һәм кирәкле булу;
- яшьләргә үзләрен реализацияләү өчен мохит;
- коммуникацияләрнең яңа форматы.

Программа чаралары федераль күрсәткечләргә ирешү өчен шартлар булдыруга юнәлтелгән:

- Балалар һәм яшьләрнең сәләтләрен һәм талантларын ачыклау, аларга ярдәм итү һәм үстерү системасының нәтиҗәлелеге;
- Ирекле ярдәмчелек (волонтерлык) эшчәнлеге белән шөгыльләнүче гражданнар өлеше.
- Гармонияле үсеш алган һәм социаль җаваплы шәхес тәрбияләү өчен шартлар.
- Яшьләрнең мәдәни чараларга йөрү саны.

Хәзерге вакытта Тукай муниципаль районында 50000нән артык кеше яши. 14 яшьтән 35 яшькә кадәрге яшьләр саны 11 000 кешедән артык.

Авыл яшьләренең, социаль төркем буларак, тулы мәгънәсендә үз социаль хәле юк. Ул хәзерге яшь буынның барлык проблемалары белән үсеш дәрәҗәсен чагылдыра торган яшь төркемен барлыкка китерә. Авылда алар тагын да ачыграк күренә. Авыл җирлегендәге яшьләр арасында тормыш дәрәҗәсенең гомуми кимүе, эшкә урнашу өчен шартлар булмау, мәдәни ихтыяҗларның үсмәве, үз һәм чит кешеләрнең әхлакый бәяләренең түбән булуы аеруча кискен тора. Ә моның нәтиҗәсе – иҗади хезмәт эшчәнлегенә игътибар итмәү, җәмгыятьнең торышы өчен җаваплылык кимү, аннан читләшү.

Бүгенге көндә проект эшчәнлеген үстерү һәм авыл яшьләре арасында эшмәкәрлекне үстерү мөһим бурыч булып тора. Ә бу алары социаль проектлауга, бизнес-планлаштыруга өйрәтүдән башка мөмкин түгел. Хәзер моны интернет челтәрендә дистанцион укыту ярдәмендә эшләргә мөмкин.

Районның төрле өлкәләрдә (мәгариф, сәламәтлек саклау, элемтә, транспорт һ.б.) социаль-икътисадый үсеше, авыл районнарында яшәү рәвешен модернизацияләү һәм эшчәнлекнең перспективалы юнәлешләре нәтиҗәсендә аларның җәлеп итүчәнлеген арттыру нәкъ менә авыл җирендә үз киләчәген төзергә теләгән авыл яшьләре өчен оптималь мөмкинлекләр булдырырга мөмкинлек бирәчәк.

## 2. Программаның төп максатлары һәм бурычлары

Программаның максаты – Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыру.

Әлеге максатка ирешү өчен түбәндәге бурычлар хәл ителергә тиеш:

1. Яшьләрнең социаль үсеше белән идарә итү, республиканың конкурентлык сәләтен ныгытуда аның иҗади потенциалыннан файдалану, яшь буынның тормыш сыйфатын яхшырту өчен оптималь шартлар тәэмин итү;
2. Авыл яшьләренең социаль һәм икътисадый активлыгын арттыру өчен шартлар тудыру;
3. Патриотик тәрбия системасын үстерү һәм модернизацияләү;
4. Ирекле лек ярдәмчелеккә (волонтерлыкка) ярдәм итү һәм үстерү.

## 3. Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары

Районның җирле бюджеты хисабына программаны финанслауның гомуми күләме 17 612 700 сум тәшкил итә.

Программаны финанслау күләме фаразланган характерда һәм тиешле елга һәм план чорына бюджет проектын формалаштырганда ел саен төгәлләштерелергә тиеш.

Республика, федераль бюджет һәм бюджеттан тыш чыганаклардан средстволар ел саен төзелә торган шартнамәләр һәм килешүләр нигезендә билгеләнәчәк.

## 4. Гамәлгә ашыру еллары буенча планлы күрсәткечләрне расшифровкалау белән программаның максатчан күрсәткечләре исемлеге

| № | Критерий исеме | Үлчәү берәмлеге | 2025 ел | 2026 ел | 2027 ел |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Мәдәни-ял чараларында катнашучы яшьләр саны | кеше | 6200 | 6250 | 6300 |
| 2 | Ирекле ярдәмчеләр эшчәнлегендә катнашучы яшьләр саны | кеше | 550 | 600 | 650 |
| 3 | Яшьләргә гражданлык һәм патриотик тәрбия бирүгә юнәлдерелгән чараларда катнашучы яшьләр саны | кеше | 800 | 830 | 860 |
| 4 | Сәламәт яшәү рәвешенә юнәлдерелгән чараларда катнашучы яшьләр саны | кеше | 6000 | 6100 | 6200 |
| 6 | Балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре эшчәнлегендә катнашучы яшьләр саны | кеше | 2600 | 2650 | 2700 |

**Программа чараларын тормышка ашыру мөмкинлек бирәчәк:**

- авылда социаль-икътисади үзгәртеп коруларда яшьләрнең ролен арттырырга;
- яшьләрнең интеллектуаль, әхлакый һәм иҗади потенциалын арттырырга;
- яшь буын арасында милли үзаңны, гражданлык һәм патриотизмны үстерергә;
- авыл яшьләрен грант нигезендә конкурсларда катнашырга, үз эшләрен башларга, аз чыгымлы һәм нәтиҗәле программалар һәм проектлар кертергә мөмкинлек бирәчәк;
- авыл яшьләренең районның социаль-икътисадый үсеше белән кызыксынуын һәм аның бу процесста катнашырга әзерлеген арттырачак;
- авыл җирлегендә уңай демографик тенденцияләрне үстерергә һәм ныгытырга;
- авыл җирлегендә социаль киеренкелек дәрәҗәсен киметергә;
- авыл яшьләренең шәһәргә күчүен киметергә.

**«2025-2027 елларга Тукай муниципаль районының авыл яшьләре» район программасын тормышка ашыру буенча чаралар**

| № | Чаралар исеме | Финанс чараларын еллар буенча бүлү (сумнарда) | | | Финанслау чыганагы | Башкаручы |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | 2025 | 2026 | 2027 | | |
| 1. | «Юмор-Шоу» юмористик сәнгать фестивале | 100000 | 100000 | 100000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 2. | Яшьләр көне | 45000 | 45000 | 45000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 3. | «Халкым минем» сәнгать смотры | 90000 | 90000 | 90000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 4. | «Сабантуй гүзәле» конкурсы | 50000 | 50000 | 50000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 5. | «Иделкәем & Кариев варислары» - балалар-яшүсмерләр театр коллективларының төбәкара смотр-конкурсы | 50000 | 50000 | 50000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 6. | «Битлек» театр фестивале | 120000 | 120000 | 120000 | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ | «Мәдәният һәм ял үзәге» МБУ |
| 7. | «Парад профессий» район конкурсы | 10000 | 10000 | 10000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 8. | Бөтенроссия робот техникасы олимпиадасында катнашу | 50000 | 50000 | 50000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 9. | «Иң яхшы әйдаман» бәйгесе | 10000 | 10000 | 10000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 10. | «Ел символы» район декоратив-гамәли иҗат конкурсы | 53000 | 53000 | 53000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 11. | Укучылар үзидарәсен үстерүгә юнәлдерелгән чаралар | 50000 | 50000 | 50000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 12. | «Тукай йолдызлары» район балалар иҗаты фестивале | 75000 | 75000 | 75000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 13. | «Сәхнә йолдызлары» район театр сәнгате фестивале | 50000 | 50000 | 50000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» |

| | | |
|---|---|---|
| 14. | «Нәни йолдызлар» район балалар иҗаты фестивале | 87000 |
| 15. | Республика театр сәнгате конкурсларында катнашу | 50000 |
| 16. | «Без бергә» республика балалар иҗаты фестиваленда катнашу | 50000 |
| 17. | Мәктәп ЗТК лигасы | 50000 |
| 18. | «Тату сыйныф серләре» республика бәйгесендә катнашу | 70000 |
| 19. | «Иң яхшы мәктәп ашханәсе» республика конкурсында катнашу | 37000 |
| 20. | Тукай муниципаль районының «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр) клубы» муниципаль бюджет учреждениесен тоту һәм яшьләр чараларын үткәрү | 4773900 |
| **БАРЛЫГЫ:** | | 5870900 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | МБББУ | [illegible] |
| 87000 | 87000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән [illegible] эшләр үзәге» МБББУ |
| 50000 | 50000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 50000 | 50000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 50000 | 50000 | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ | «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» МБББУ |
| 70000 | 70000 | Мәгариф идарәсе | Мәгариф идарәсе |
| 37000 | 37000 | Мәгариф идарәсе | Мәгариф идарәсе |
| 4773900 | 4773900 | «Яшәү урыны буенча яшьләр (яшүсмерләр)» клубы МБУ | Яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлеге |
| 5870900 | 5870900 | | |